БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 04 2021 ел № 148

«Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Балтач муниципаль районының психологик – педагогик хезмәте турында нигезләмәне раслау хакында

Белем бирү процессында катнашучыларга психологик, социаль-педагогик ярдәм күрсәтүне камилләштерү һәм Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия утырышының 2020 елның 4 августындагы ПР-166 ДСП номерлы беркетмәсенең 1.11 пунктын үтәү максатларында, «Татарстан Республикасы мәгариф системасының муниципаль психологик-педагогик хезмәте турында үрнәк нигезләмәне җибәрү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 15094/20 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хатын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Балтач муниципаль районының психологик – педагогик хезмәте турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Террорчылыкка каршы комиссиянең 2020 елның 5 мартындагы 1 номерлы беркетмәсе нигезендә, Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларында белем алучыларны психологик яктан тәэмин итүне оештыру өчен:

2.1. Түбәндәге учреждениеләрне төп мәгариф оешмалары итеп билгеләргә:

- «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы психологик – педагогик хезмәт;
- МБГБУ «Балтач гимназиясе»;
- ГБМБУ «Балтач урта гомуми белем мәктәбе»;
- ГБМБУ «Норма урта гомуми белем мәктәбе»;
- МБГБУ «Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе»;
- МБГБУ «Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе»;
- МБГБУ «Бөрбаш урта гомуми белем мәктәбе»;
- МБГБУ «Нөнәгәр гомуми урта белем мәктәбе»;

2.2. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ

каршындагы психологик – педагогик хезмәткә МБГБУ «Куныр урта гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Яңгул урта гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Пыжмара төп гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Сосна төп гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Субаш төп гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Арбор төп гомуми белем мәктәбе»н беркетергә.

2.3 ГБМБУ «Норма урта гомуми белем мәктәбе»нә МБГБУ «Кече Лызи урта гомуми белем бирү мәктәбе»н беркетелергә;

2.4. МБГБУ «Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе»нә МБГБУ «Урта Көшкәт гомуми урта белем бирү мәктәбе»н, МБГБУ «Түнтәр урта гомуми белем мәктәбе»н беркетелергә;

2.5. МБГБУ «Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе»нә «МБГБУ «Шубан төп гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Б.С. Рәхимов исемендәге Кенә төп гомуми белем мәктәбе»н беркетергә;

2.6. МБГБУ «Бөрбаш урта гомуми белем мәктәбе»нә МБГБУ «Салавыч күппрофильле лицее»н беркетергә;

2.7. МБГБУ «Нөнәгәр гомуми урта белем мәктәбе»нә МБГБУ «Смәел урта гомуми белем мәктәбе»н, МБГБУ «Шеңшеңәр төп гомуми белем бирү мәктәбе»н беркетергә.

3. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Балтач муниципаль районының психологик – педагогик хезмәтен булдыру турында» 2014 елның 18 сентябрендәге 327 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Балтач муниципаль районының психологик – педагогик хезмәте турында Нигезләмә үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5 . Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
«07» 04. 2021
148 номерлы карарына
кушымта

**«Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ каршындагы Балтач муниципаль районының психологик – педагогик хезмәте турында Нигезләмә**

## 1. Төп төшенчәләр

1.1. Әлеге нигезләмә психологик-педагогик хезмәт эшчәнлегенең оештыру-методик нигезен билгели (алга таба – хезмәт)

1.2. Муниципаль психологик-педагогик хезмәт мәгариф идарәсенең ведомство буйсынуында. Психологик-педагогик хезмәт составына белем бирү процессында катнашучыларга ярдәм күрсәтүче педагог-психологлар һәм логопед керә.

Белем бирү процессының субъектлары - белем алучылар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), педагоглар, мәгариф оешмасы администрациясе.

## 2. Гомуми нигезләмәләр

2.1. Татарстан Республикасы мәгариф системасының муниципаль психологик-педагогик хезмәте турында әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясы нигезендә эшләнде һәм Хезмәт эшчәнлегенең максатын, бурычларын, структурасын, составын, оештыру-методик нигезен билгели. Хезмәт мәгарифнең өстенлекле максатлары һәм бурычлары кысаларында булдырыла, аларны хәл итү белем бирү процессының барлык субъектларына психологик-педагогик ярдәмнең комплекслы якын килүенең тәңгәл (адекват) системасын төзүне таләп итә.

2.2. Хезмәт үз эшчәнлегендә балалар хокукларын яклау өлкәсендә халыкара актларга, Россия Федерациясе Конституциясенә, Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенә, «Мәгариф турында», «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законнарга, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Мәгариф идарәсе» МКУ боерыкларына һәм инструкцияләренә һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

Хезмәт эшчәнлегенең төп принциплары - бала мәнфәгатьләренең өстенлеге, ярдәм күрсәтүне оештыруда өзлексез һәм комплекслы якын килү, ярдәм

күрсәтүнең һәм хезмәтләр күрсәтүнең киңәш бирү характеры, алынган мәгълүматның конфиденциальлеген үтәү (аны гамәлдәге законнар кысаларында куллану).

Хезмәтне булдыру турында карар Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә һәм норматив хокукый документ белән беркетелә.

2.3. Хезмәтнең Составы

Хезмәт составына белем бирү процессы субъектларына педагогик, психологик ярдәм күрсәтә торган психолог, педагог-психолог, логопед керә.

Хезмәт эшчәнлеген тәэмин итү өчен таләп ителә торган штат берәмлекләре саны территориаль урнашу спецификасы, балалар санының һәм аларның психологик-педагогик ярдәмгә ихтыяҗы нигезендә билгеләнә.

«Россия Федерациясендә белем бирүнең гамәли психологиясе хезмәтенең торышы һәм үсеш перспективалары турында»1995 елның 29 мартындагы 7/1 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә педагог-психологлар ставкалары саны 500 белем алучыга ким дигәндә 1 штат берәмлеге итеп билгеләнә.

Оештыру-методик җитәкчелек итү Хезмәт җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

2.4. Хезмәт эшчәнлеген матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итү аның территориясендә Хезмәт эшли торган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 3. Максатлар һәм бурычлар

3.1. Максатлары:

– Белем алучыларга, аларның сәләтләренә, омтылышларына, мәнфәгатьләренә, сәламәтлеге торышына карап, психологик-педагогик ярдәм күрсәтү;

- Белем алучыларның һәм белем бирү процессында катнашучыларның физик, психик, социаль сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыручы бердәм белем бирү мохите булдыру;

– Педагогик хезмәткәрләргә, ата-аналарга (законлы вәкилләргә) белем алучыларны тәрбияләүдә ярдәм итү.

3.2. Бурычлар:

- Әлеге Хезмәт төзелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә педагог-психолог булмаган мәгариф оешмаларында белем бирү системасының социаль-психологик мониторингын оештыру һәм үткәрү;

- Мәгариф оешмаларының заявкалары (психологик абонемент) буенча, социаль-психологик мониторинг мәгълүматларын анализлау нигезендә һәр баланың потенциаль мөмкинлекләрен ачуга юнәлдерелгән белем бирү процессына

психологик яктан ярдәм итә бару, «риск төркеме»ндәге белем алучыларны ачыклау;
- Хезмәт компетенциясе кысаларында ведомство карамагындагы территориядә мәгариф оешмалары эшчәнлегенә мәгълүмат бирү һәм оештыру буенча ярдәмне гамәлгә ашыру;
- үстерү һәм коррекцияләү буенча психологик-педагогик эш программаларын эшләү;
- Белем бирү процессы субъектлары белән психологик-педагогик эшне оештыру һәм үткәрү.

3.3. Әлеге максатларга һәм бурычларга ирешү өчен хезмәт түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:
– Балаларның психологик, физик үсеше, социаль яшәү шартларын диагностикалау (укуның бөтен чоры дәвамында укучыларны психологик - педагогик өйрәнү, шәхеснең шәхси үзенчәлекләрен һәм омтылышларын, укыту һәм тәрбия процессында, һөнәри үзбилгеләнешендә аның потенциаль мөмкинлекләрен билгеләү, шулай ук укытуда, үсештә, социумда җайлашуда тайпылышларның сәбәпләрен һәм механизмнарын ачыклау);
– Балалар белән психологик коррекцияләү һәм үстерү буенча эш (балачак яшендә шәхес формалаштыру процессына актив йогынты ясау һәм аның педагог - психологлар, логопедлар, социаль педагоглар һәм башка белгечләрнең уртак эшчәнлеге нигезендә тормышка ашырыла торган индивидуальлеген саклау);
– Психологик-педагогик профилактик эшчәнлек (белем алучыларда нормадан тайпылу (девиация), җайлашу сәләтен югалту (дезадаптация) күренешләре барлыкка килүне кисәтү, аларга социаль ярдәм күрсәтү, педагогик хезмәткәрләргә, ата-аналарга (законлы вәкилләргә) баланы социаль мохиттә тәрбияләү, укыту, үстерү һәм җайлаштыру мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтү буенча киңәшләр эшләү);
– Консультатив эшчәнлек (белем алучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) һәм белем бирү процессында катнашучыларга үстерү, тәрбия һәм белем бирү, физик һәм психологик сәламәтлекне саклау, педагогик, психологик консультацияләр ярдәмендә аны ныгыту чараларын һәм ысулларын куллану мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтү);
- Мәгърифәтчелек эшчәнлеге (белем алучыларда һәм аларның ата-аналарында (законлы вәкилләрдә), педагогик хезмәткәрләрдә һәм мәктәп администрациясендә психологик, валеологик, логопед, медицина белемнәренә ихтыяҗ, аларны үз үсеше мәнфәгатьләрендә куллану теләген формалаштыру; һәр яшь этабында белем алучыларның тулы шәхси үсеше һәм үзбилгеләнеше өчен шартлар тудыру, шулай ук шәхес булуда һәм интеллектны үстерүдә мөмкин булган тайпылышларны вакытында кисәтү; сәламәт яшәү рәвешенә карата карашларын һәм тормыштагы өстенлекләрен формалаштыру).

## 4. Хезмәт структурасы һәм идарәсе

4.1. Психологик-педагогик хезмәт «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең ведоство карамагында.

4.2. Идарә итү эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы башкара, ул Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе белән килештереп, Хезмәт җитәкчесе вазыйфасына билгели.

4.3. Хезмәт җитәкчесе: Хезмәт эшчәнлеге өчен тулысынча җавап тота; Хезмәт хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүлә;

4.4. Җитәкче Хезмәт исеменнән ышаныч кәгазеннән башка үз компетенциясе чикләрендә дәүләт органнарында, предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә аның мәнфәгатьләрен яклый.

4.5. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Хезмәт җитәкчесе тәкъдиме буенча Психология-педагогия хезмәте структурасын, аның штат һәм квалификация составын билгели һәм раслый, хезмәт килешүе (контракт) нигезендә хезмәт хезмәткәрләрен вазыйфага яллый (билгели) һәм аны вазыйфасыннан азат итә.

4.6. Хезмәтнең структурасында түбәндәгеләр бар:
методик хезмәт;
психологик-педагогик хезмәт;
логопед хезмәте.

## 5. Белем бирү процессында катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Белем бирү процессында катнашучылар булып белем алучылар, аларның әти-әниләре (законлы вәкилләре), педагогик хезмәткәрләр, педагог-психологлар тора.

5.2. Хезмәт белгечләре ярдәм сорап мөстәкыйль мөрәҗәгать иткән (16 яшькә җиткәннән соң), ата-аналар (законлы вәкилләр) инициативасы буенча килгән, башка мәгариф оешмасы, медицина учреждениесе тарафыннан җибәрелгән балалар белән эшлиләр.

5.3. Ата-аналар (законлы вәкилләр) күзәтү материаллары, балаларны укытуның, тәрбияләүнең һәм сәламәтләндерүнең тернәкләндерү (реабилитацион) алымнары белән танышырга хокуклы.

5.4. Хезмәт эшендә вазыйфасы буенча квалификация характеристикасы һәм алган белгечлек таләпләренә туры килә торган һәм белем алу турындагы документлар белән расланган һөнәри квалификациясе булган белгечләр катнаша.

5.5. Хезмәт хезмәткәрләре һөнәри эшчәнлектә түбәндәгеләргә бурычлы:

– катгый рәвештә һөнәри компетенция чикләрендә генә сораулар карарга һәм

карар кабул итәргә;

– белем алучыларны, тәрбияләнүчеләрне һәм белем бирү даирәсенең башка субъектларын үстерү буенча барлык проблемаларны һәм мәсьәләләрне хәл итүдә баланың тормыш мәнфәгатьләреннән һәм эмоциональ иминлегеннән чыгып эш итәргә;

– һөнәри квалификация дәрәҗәсен даими күтәрергә;

– психологик фән казанышлары турында хәбәрдар булырга;

## 6. Психологик-педагогик хезмәтнең локаль актлары

- Психологик-педагогик хезмәт турында нигезләмә;
– «ППХ»ның эш планнары (уку елына);
- хезмәткәрләрнең уку елына индивидуаль эш планнары;
– контроль буенча документлар (хезмәтнең фәнни һәм гамәли эшенең барышын һәм нәтиҗәләрен контрольдә тоту буенча документлар; хезмәтнең эш юнәлешләре буенча аналитик материал);
- хезмәтнең утырышлары беркетмәләре;
- кирәкле укыту-методик документлар.